Татарстан Республикасы Ютазы муниипаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР

25.09.2023 ел №21

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле
авыл җирлеге Советының 2023 елның 01 мартындагы 3 санлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль Законга, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»гы 1-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 01 мартындагы 3 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл
җирлеге башлыгы А.Г. Дәүләтгәрәев